

«Известия Мордовии»га Эрьзя музее директоры Людмила Нарбекова сойләгәнчә, «Федот Сычков – шатлык рәссамы» кvргәзмәсен Пензада бер ел элек, якташыбыз, уникаль рәссамнын 150 еллыгына багышлап кvрсәтергә ниятләнгән булган.
Остәвенә, пензалылар vзләре дә рәс-самнын әсәрләрен кvрсәтергә теләк белдергәннәр. Бу анлашыла да, чонки кvрше олкәдә яшәvчеләр Сычковны vз якташлары дип саный алар. Эш шунда ки, рәссам туган Кочелай авылы элек Пенза губернасынын Наровчат оязенә караган.      Моннан тыш, 1918 елда Сычков хезмәттәше белән Октябрь революциясе еллыгына багышланган бәйрәм бизәлешен булдыру һәм Пенза губернасында беренче сәнгать кvргәзмәсен оештыру белән шогыльләнә. Ә тагын, булган мәгълvматларга караганда, ул этюдларны Пенза янындагы Император сәнгать академиясе буенча хезмәттәше һәм сыйныфташы Иван Горюшкин-Сорокопудов дачасында язган. Әмма пандемия аркасында юбилей кvргәзмәсен кичектергән булганнар. Тик менә хәзер, 30 июльдә ул, ниһаять, Пенза олкә картиналар галереясендә ачылды. Тамашачылар игътибарына Эрьзя музее жыелмасыннан Федот Сычковнын кырык әсәре тәкъдим ителде. Сентябрь ахырына кадәр Пензада кvренәчәк.
Пенза картиналар галерея-се директоры Кирилл Застрожный кунакларны сә-ламләп, нәтижәле музей хезмәттәшлегенен активлашуын канәгатьлек белән билге-ләп vтте. Беренче кvргәзмәдә Пенза олкәсенен мәдәният һәм туризм министры Татьяна Курдова да булды.
Вернисажга килгән һәркем очен аерым сюрприз булып жирле мордва фольклор коллективынын чыгышы булды, ул кvргәзмә кинлекләре атмосферасын милли тосләр белән тулыландырды.
Сvз унаенда, юбилей экспозициясенә кертелгән эшләрнен кvбесе музей запасникларында саклана һәм тамашачыларга сирәк кvрсәтелә.

**Н.ХӘЛИЛ әзерләде**